РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БОЛЬШЕТАРХАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ТАРХАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422386 с. Большие Тарханы, ул. Горького, 7

422386 Олы Тархан авылы, Горький урамы, 7

тел. (884373) 51-2-43, факс 51-2-43, e-mail: Btar.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606555585, ИНН/КПП 1638001504/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .11. 2023** **№ 29-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Олы Тархан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль Законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Тархан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Тархан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проектын (алга таба – Устав проекты) беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Устав проекты буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Олы Тархан авылы, Горький урамы, 7 йорт; Куйбышев урамы, 19 йорт; Ленин урамы, 24а йорт; Такташ урамы, 10 йорт; Түбән Тархан авылы, Чернышевский урамы, 13 йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru.
7. Устав проекты буенча 2023 елның 22 декабренә 14:00 сәгатьтә Олы Тархан авыл мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар билгеләргә.
8. Устав проекты буенча Комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Олы Тархан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Устав проектын тикшерү һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.
9. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тархан авыл җирлеге башлыгы урынбасары Г.Р. Якатовага йөкләргә.

**Җитәкче урынбасары** **Г.Р. Якатова**